Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советы
КАРАР

2023 елның 28 апреле №89

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) физик затның вафат булган көненнән яисә аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаган булса, йә варисларның берсенең дә мирас итеп алырга хокукы булмаса яисә барлык варислары варислардан читләштерелгән булса, йә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, йә барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән булса;

2) салым түләүченең - гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок тәмамлану.

2. Гамәлдән чыккан дип танырга:

- «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 74 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Советы карары.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Кызыл Армия урамы, авыл үзәге;

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы Колхоз ур. 16а йроты,китапханә бинасы.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлен

2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районының Сөйки авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы, Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районының
«Сөйки авыл җирлеге Советы рәисе П.В. Сорокин